СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 265 от 09.11.2018
на № _________от ______________

# КАРАР

Беренче укылышта 2019 елга һәм 2020-2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты турында

Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палаты рәисе Ш.Ә.Сөнгәтовның докладын тыңлаганнан һәм 2019 елга һәм 2020-2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты проектын караганнан соң, Татарстан Республикасы Саба муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Беренче укылышта 2019 елга һәм 2020-2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетын расларга (теркәлә).

2. 2019 елга һәм 2020-2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты буенча җәмәгать тыңлауларын 2018 елның 10 декабренә билгеләргә, үткәрү урыны итеп Саба муниципаль районы Башкарма Комитетының утырышлар залын, үткәрү вакытын 9.00 сәг. дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы
Саба муниципаль район Советының
09.11.2018 ел, 265 номерлы карары белән

# 2019 ЕЛГА ҺӘМ 2020-2021 ЕЛЛАРНЫҢ ПЛАН ЧОРЫНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БЮДЖЕТЫ ПРОЕКТЫ

Статья 1

1. 2019 елга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 1 030 615,510 мең сум итеп;

2) Саба муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 1 030 615,510 мең сум итеп;

3) Саба муниципаль районы бюджеты кытлыгын 0,000 мең сум итеп.

2. 2020 елга һәм 2021 елга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга :

1) Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2020 елга 1 035 105,250 мең сум һәм 2021 елга 1 039 898,850 мең сум итеп;

2) Саба муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен

- 2020 елга 1 035 105,250 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 8 867,300 мең сумм итеп;

- 2021 елга 1 039 898,850 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 17 836,400 мең сум итеп;

3) 2020 һәм 2021 елларга Саба муниципаль районы бюджеты кытлыгын 0,000 мең сум итеп.

3. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Саба муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын элеге Карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 2

1. Саба муниципаль районы эчке муниципаль бурычының ин югары чиген тубэндэгечэ расларга:

- 2020 елның 1 гыйнварына 0,000 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген 0,000 мең сум итеп;

- 2021 елның 1 гыйнварына 0,000 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген 0,000 мең сум итеп;

- 2022 елның 1 гыйнварына 0,000 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген 0,000 мең сум итеп.

2. Саба муниципаль районы эчке муниципаль бурычының иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

- 2019 елга - 0,000 мең сум күләмендә;
- 2020 елга - 0,000 мең сум күләмендә;
- 2021 елга - 0,000 мең сум күләмендә.

Статья 3

Саба муниципаль районы бюджетында 2019 елга, 2020 һәм 2017 еллар план чорына керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен элеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Статья 4

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Саба муниципаль районы бюджет системасының бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге Карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 5

2019 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына Саба муниципаль районы муниципаль унитар предприятияләре табышының, 2018 ел йомгаклары буенча салымнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан сон калган өлеше тиешенчә, 2019 елның 1 июленә кадэр чиста табышның 30 проценты күләмендә кертелә дип билгеләнә.

Статья 6

1. Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең төп администраторлары исемлеген элеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Саба муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген элеге Карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 7

1. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Саба муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Карарга 6 нче кушымта нигезендә расларга.

2. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Саба муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясе бүлеклэре, булекчәләре, максатчан статьялары (Саба муниципаль районының муниципаль программаларына, муниципаль программалардан тыш юнэлештэге эшчэнлеккэ) һәм чыгым төре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Саба муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялары (Саба муниципаль районының муниципаль программаларына, муниципаль программалардан тыш юнэлештэге эшчэнлеккэ), бюджет чыгымнары классификациясе бүлеклэре, булекчәләре, чыгым төре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Карарга 8 нче кушымта нигезендә расларга

4. Саба муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган гомуми кулэмен 2019 елга 15 701,508 мең сум, 2020 елга 15 633,672 мең сум,2021 елга 15 633,672 мең сум кулэмендэ расларга.

Статья 8

Җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүленешен түбәндәгечә расларга:

- 2019 елга 16 552,400 мең сум күләмендә;
- 2020 елга 8 187,800 мең сум күләмендә;
- 2021 елга 9 598,300 мең сум күләмендә әлеге Карарга 9 нче кушымта нигезендә.

Статья 9

Хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу дәүләт хокукларын тормышка ашыру буенча җирлек бюджетларына субвенция күләмен түбәндәгечә расларга:

- 2019 елга 1 771,300 мең сум күләмендә;

- 2020 елга 1 777,300 мең сум күләмендә;

-2021 елга 1 842,600 мең сум күләмендә әлеге Карарга 10 нче кушымта нигезендә.

Статья 10

Гражданлык хәлен дәүләт теркәү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирлек бюджетларына субвенция күләмен түбәндәгечә расларга:

- 2019 елга 99,100 мең сум күләмендә;

- 2020 елга 102,500 мең сум күләмендә;

- 2021 елга 105,700 мең сум күләмендә әлеге Карарга 11 нче кушымта нигезендә.

Статья 11

Саба муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган субсидияләр күләмен тубәндәгечә исәпкә алырга:

1) 2019 елга 431 455,100 мең сум күләмендә, шул исәптән:

- муниципаль район составына керүче җирлек бюджетларының бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә субсидияләр һәм башка төрле бюджетара трансфертлар белән тәэмин итүне 30 811,500 мең сум күләмендә;

- муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыруга, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап тоту һәм тәрбияләү өчен шартлар тудыру, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын оештыруга субсидияләр бирүне 400 643,600 мең сум күләмендә.

2) 2020 елга 432 448,800 мең сум , 2021 елга 428 755,100 мең сум, шул исәптән:

- муниципаль район составына керүче җирлек бюджетларының бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә субсидияләр һәм башка төрле бюджетара трансфертлар белән тәэмин итүне 2020 елга 30 828,700 мең сум, 2021 елга 31 270,300 мең сум күләмендә;

- муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыруга, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап тоту һәм тәрбияләү өчен шартлар тудыру, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын оештыруга субсидияләр бирүне 2020 елга 401 620,100 мең сум,2021 елга 397 484,800 мең сум күләмендә.

Статья 12

Саба муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр күләмен түбәндәгечә исәпкә алырга:

1) 2019 елга 261 538,900 мең сум кулэмендә, шул исәптән:

- җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан шәһәр җирлекләренә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр 730,800 мең сум куләмендә;

- җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан авыл җирлекләренә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 574,400 мең сум куләмендә;

- муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми

белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен субвенцияләрне 165 555,600 мең сум күләмендә;

- муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен субвенцияләрне 82 671,400 мең сум күләмендә;

- мәгариф өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 341,400 мең сум күләмендә;

- белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 4 597,200 мең сум күләмендә;

- балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 715,600 мең сум күләмендә;

- административ комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 363,400 мең сум күләмендә;

- дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 341,400 мең сум күләмендә ;

- архив эше өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 49,700 мең сум күләмендә;

- опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне оештыру һәм башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 940,500 мең сум күләмендә;

- административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 0,500 мең сум күләмендә;

- хайван авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 1 123,900 мең сум күләмендә, шул исәптән Себер түләмәсе булган үләт базларын һәм биотермик чокырлар тотуга 1 018,300 мең сум күләмендә, хуҗасыз хайваннарны тоту, карау һәм аларның санын җайга салуга 105,600 мең сум күләмендә;

- йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм сакланган территорияләрдә һәм биналарда, тикшеренүләрендә лаборатор методларын кулланып үткәрелә торган йогышсызландыру, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар үткәрүне оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 479,200 мең сум күләмендә;

- муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүматларны җыю вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенция 2,800 мең сум күләмендә;

- дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 34,000 мең сум күләмендә;

- хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 1 771,300 мең сум күләмендә;

- гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 1 137,100 мең сум күләмендә;

- Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча субвенцияләрне 9,600 мең сум күләмендә.

2) 2020 елга 261 609,200 мең сум күләмендә, 2021 елга 261 410,400 мең сум күләмендә, шул исәптән:

- җирлекләрнең финанс ярдәме региональ фондыннан шәһәр җирлекләренә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 597,900 мең сум күләмендә, 2021 елга 445,300 мең сум күләмендә;

- җирлекләрнең финанс ярдәме региональ фондыннан авыл җирлекләренә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 548,000 мең сум күләмендә, 2021 елга 198,000 мең сум күләмендә;

- муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен субвенцияләрне 2020 елга 165 555,600 мең сум күләмендә, 2021 елга 165 555,600 мең сум күләмендә;

- муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен субвенцияләрне 2020 елга 82 671,400 мең сум күләмендә, 2021 елга 82 671,400 мең сум күләмендә;

- мәгариф өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 341,400 мең сум күләмендә, 2021 елга 341,400 мең сум күләмендә;

- белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 4 758,100 мең сум күләмендә, 2021 елга 4 933,700 мең сум күләмендә;

- балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 716,700 мең сум күләмендә, 2021 елга 717,800 мең сум күләмендә;

- административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 363,400 мең сум күләмендә, 2021 елга 363,400 мең сум күләмендә;

- дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 341,400 мең сум күләмендә, 2021 елга 341,400 мең сум күләмендә;

- архив эше өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 49,700 мең сум күләмендә, 2021 елга 49,700 мең сум күләмендә;

- опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне оештыру һәм башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 940,500 мең сум күләмендә, 2021 елга 940,500 мең сум күләмендә;

- административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 0,500 мең сум күләмендә, 2021 елга 0,500 мең сум күләмендә;

- хайван авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән саклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга һәм 2021 елга, ел саен 1 123,900 мең сум күләмендә, шул исәптән Себер түләмәсе булган үләт базларын һәм биотермик чокырлар тотуга 1 018,300 мең сум күләмендә, хуҗасыз хайваннарны тоту, карау һәм аларның санын җайга салуга 105,600 мең сум күләмендә;

- йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм сакланган территорияләрдә һәм биналарда, тикшеренүләрендә лаборатор методларын кулланып үткәрелә торган йогышсызландыру, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар үткәрүне оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 497,800 мең сум күләмендә, 2021 елга 518,400 мең сум күләмендә;

- муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүматларны җыю вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияне 2020 елга 2,800 мең сум күләмендә, 2021 елга 2,800 мең сум күләмендә;

- дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 34,000 мең сум күләмендә, 2021 елга 34,000 мең сум күләмендә;

- хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 1 777,300 мең сум күләмендә, 2021 елга 1 842,600 мең сум күләмендә;

- гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга субвенцияләрне 2020 елга 1 176,300 мең сум күләмендә, 2021 елга 1 213,700 мең сум күләмендә;

- Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча субвенцияләрне 2020 елга 10,000 мең сум күләмендә, 2021 елга 10,600 мең сум күләмендә.

Статья 13

Татарстан Республикасы бюджетыннан Саба муниципаль районы бюджетына кергән муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә финанс ярдәменең региональ фондыннан дотацияне түбәндәгечә исәпкә алырга:

- 2019 елга 263 052,400 мең сум күләмендә, шул исәптән, акчалата чагылышта 16 552,400 мең сум күләмендә, аларны физик затлар керемена салымнан күчерүләрнең өстәмә нормативлары 246 500,000 мең сум күләмендә алыштыра;

- 2020 елга 264 547,800 мең сум күләмендә, шул исәптән, акчалата чагылышта 8 187,800 мең сум күләмендә, аларны физик затлар керемена салымнан күчерүләрнең өстәмә нормативлары 256 360,000 мең сум күләмендә алыштыра;

- 2021 елга 277 751,200 мең сум күләмендә, шул исәптән, акчалата чагылышта 9 598,300 мең сум күләмендә, аларны физик затлар керемена салымнан күчерүләрнең өстәмә нормативлары 268 152,900 мең сум күләмендә алыштыра.

Статья 14

2019 елга Саба муниципаль районының Юл фонды бюджет ассигнованиеләре күләмен 12 600,000 мең сум күләмендә, 2020 елга – 13 200,000 мең сум, 2021 елга 13 600,000 мең сум күләмендә расларга һәм аларны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү муниципаль программасын тормышка ашыруга юнәлтергә.

Статья 15

1. Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары 2019 елда яңа кертелә торган объектлар санынннан тыш, муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль учреждениеләр эшләүчеләрнең санын, шулай ук аларны тотуга китуче чыгымнарны арттыруга китерерлек карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2019 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр эшләүчеләрнең санын арттыруга китерерлек карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

Статья 16

Саба муниципаль районы бюджетының калган өлеше  Саба муниципаль районы исеменнән товарлар кайтаруга эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактлар шартлары нигезендә, 2018 елда әлеге муниципаль контрактларга түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмаган суммасынның артмаган күләмдә 2019 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

Статья 17

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының Саба районы буенча Казначылык Департаментының территориаль бүлеге, төзелгән килешүләр нигезендә, Саба муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

Статья 18

Әлеге Карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Статья 19

Әлеге Карарны «Саба таңнары» район газетасында һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://saby.tatarstan.ru.